| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ<br>РАЙОН СОВЕТ<br>НИЖНЕНАРАТБАШСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ТҮБӘН НАРАТБАШ<br>АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
|---|---|---|

РЕШЕНИЕ — КАРАР

«12» февраль 2019 ел — № 64-1

«Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Түбән Наратбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Түбән Наратбаш авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. ТР Буа муниципаль районы авыл җирлегенең «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Түбән Наратбаш авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре турында» 2013 елның 18 февралендәге 1-36 номерлы карары (Карарның 2016 елның 28 июнендәге 15-3 номерлы, 2017 елның 23 сентябрендәге 38-1 номерлы редакцияләрендә) белән расланган «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Түбән Наратбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 1 статья:

6 абзацны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Шәһәр төзелешен зоналарга бүлү – территориаль зоналарны ачыклау һәм шәһәр төзелеше регламентларын билгеләү максатларында муниципаль берәмлекләрнең территорияләрен зоналарга бүлү;»;

1.2. 1 статья:

7 абзацны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Шәһәр төзелеше регламенты – тиешле территориаль зоналарның чикләре эчендә билгеләнүче җир кишәрлекләрен рөхсәтле файдалану төрләре, җир кишәрлекләре өстендә һәм астында бертигез рәвештә барча булганга һәм аларда төзелеш алып бару һәм алга таба капиталь төзелеш объектларын эксплуатацияләү барышында файдалануга, җир кишәрлекләренең чик (минималь һәм (яки) максималь) зурлыклары һәм рөхсәтле төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын төзекләндерүнең чик параметрлары, җир кишәрлекләрен һәм капиталь төзелеш объктларын файдалануда чикләүләр, шулай ук чикләрендә комплекслы һәм тотрыклы үсеш буенча эшчәнлек башкару күздә тотылган территорияләргә кулланылган, тиешле территориянең коммуналь, транспорт, социаль

инфраструктура объектлары белән минималь рөхсәт ителгән тәэмин ителеш дәрәҗәсенең исәпләнгән күрсәткечләре һәм халык өчен әлеге объектларның территориаль үтемлелеге рөхсәт ителгән максималь дәрәҗәсенең исәпләнгән күрсәткечләре;»;

1.3. 1 статья:

13 абзацны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Территорияне махсус шартларда файдалану зоналары – сакланган, санитар-саклана торган зоналар, Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектларын (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) саклау зоналары (алга таба – мәдәни мирас объектлары), мәдәни мирас объектларының саклау зоналары, су саклау зоналары, су басу, ташу зоналары, эчә торган һәм хуҗалык-көнкүреш өчен су белән тәэмин итү чыганакларын санитар саклау зоналары, саклана торган объектларның зоналары, аэродром буендагы территория, Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә торган башка зоналар;»;

1.4. 1 статья:

18 абзацны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Кызыл линияләр – гомуми файдаланыштагы территорияләрнең булган, планлаштырылган (үзгәртелә, яңадан булдырыла торган) чикләрен һәм линия объектлары урнашкан һәм (яки) линия объектларын урнаштыруга билгеләнгән территорияләрнең чикләрен аңлатучы линияләр;»;

1.5. 1 статья:

25 абзацны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Шәхси торак төзелеше объекты – җир өстендәге катлары саны өчдән дә күбрәк булмаган, биеклеге егерме метрдан артмаган, бүлмәләрдән һәм гражданнарга аларның мондый бинада яшәве белән бәйле рәвештә, көнкүреш һәм башка ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен билгеләнгән ярдәмче файдаланыштагы урыннардан торган һәм аерым күчемсез милек объектларына бүләр өчен билгеләнмәгән аерым басып торган бина. “Шәхси торак төзелеше объекты”, “торак йорт” һәм “шәхси торак йорт” төшенчәләре гамәлдәге Кодекста, башка федераль законнарда һәм Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында бер мәгънәдә кулланыла, әгәр андый федераль законнарда һәм Россия Федерациясе норматив хокукый актларында башкасы каралмаган булса. Шәхси торак төзелеше объектларына гамәлдәге Кодекс белән билгеләнгән параметрлар торак йортларга, шәхси торак йортларга бертигез дәрәҗәдә кулланыла, әгәр башкасы андый федераль законнарда һәм Россия Федерациясе норматив хокукый актларында каралмаган булса.»;

1.6. 1 статья:

27 абзацны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Капиталь булмаган төзелешләр, корылмалар – җир белән ныклы бәйләнеше булмаган һәм аларның конструктив характеристикалары аларны күчерү һәм (яки) сүтү һәм алга таба билгеләнешенә зур зыян китермичә һәм төзелешнең, корылманың (шул исәптән киосклар, япмалар һәм башка шундый төзелеш, корылмалар) төп характеристикасын үзгәртмичә яңадан җыю мөмкин булган төзелешләр, корылмалар;»;

1.7. 1 статья:

44 абзацны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Объектны эксплуатациягә кертүгә рөхсәт капиталь төзелеш объектын төзү, төзекләндерү төзелешкә рөхсәт, проект документациясе нигезендә тулы күләмдә башкарылуын, шулай ук төзелгән, төзекләндерелгән капиталь төзелеш объектының капиталь төзелеш объектын төзү, төзекләндерү таләпләренә туры килүен, төзелешкә рөхсәт алу өчен тәкъдим ителгән җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү датасына билгеләнгән, җир кишәрлеген рөхсәтле файдалану яки линия объектын төзү, төзекләндерү очрагында территорияне планировкалау проектына һәм территорияне межлау проектына (линия объектын төзү, төзекләндерү өчен территорияне планлаштыру буенча документлар әзерләү таләп ителмәгән очраклардан тыш), линия объектын урнаштыру өчен җир кишәрлеген оештыру таләп ителгәндә эксплутациягә кертүгә рөхсәт бирү очрагында территорияне планлаштыру проектына, һәм шулай ук Россия Федерациясенең җир һәм башка законнары нигезендә билгеләнгән бүтән чикләүләргә туры килүен расланучы документтан гыйбарәт;»;

1.8. 1 статья:

46 абзацны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Төзелешкә рөхсәт проект документлары шәһәр төзелеше регламенты (әлеге статьяның 1_1 өлешендә каралган очраклардан тыш), линия объекты булмаган капиталь төзелеш объектын төзү, төзекләндерүне башкарганда территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне межлау проекты (гамәлдәге Кодекс нигезендә территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне межлау проекты әзерләү таләп ителмәгән очраклардан тыш) белән билгеләнгән таләпләргә (алга таба – капиталь төзелеш объектын төзү, төзекләндерүгә таләпләр), яки линия объектын төзү, төзекләндерүне башкарганда (линия объектын төзү, төзекләндерү өчен территорияне планировкалау буенча документлар таләп ителмәгән очраклардан тыш) территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне межлау проекты белән билгеләнгән таләпләргә, урнаштыру өчен җир кишәрлеге оештыру таләп ителмәгән линия объектын төзүгә рөхсәт бирү очрагында территорияне планлаштыру проекты белән билгеләнгән таләпләргә туры килүен, һәм шулай ук капиталь төзелеш объктын андый җир кишәрлегенең рөхсәтле файдалануы нигезендә һәм Россия Федерациясенең җир һәм башка законнары нигезендә билгеләнгән чикләүләре белән җир кишәрлегендә урнашуы мөмкин булуын расланучы документтан гыйбарәт. Төзүчегә төзелешкә рөхсәт, гамәлдәге Кодекста каралган очраклардан тыш, капиталь төзелеш объектын төзүне, төзекләндерүне башкару хокукын бирә;»;

1.9. 1 статья:

50 абзацны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Капиталь төзелеш объектларын төзекләндерү (линия объектларыннан тыш) – капиталь төзелеш объектлары параметрларын, аның өлешләрен (биеклеге, катлар саны, мәйданы, күләме), шул исәптән өстәп төзү, үзгәртеп төзү, капиталь төзелеш объектын киңәйтү, шулай ук капиталь төзелеш объектының күтәреп торучы төзелеш конструкцияләрен алмаштыру һәм (яки) торгызу (андый конструкцияләрнең аерым элементларын шундыйга ук яки андый конструкцияләрнең күрсәткечләрен

яхшыртучы башка элементларга алмаштыру һәм (яки) әлеге элементларны торгызудан тыш);»;

1.10. 1 статья:

57 абзацны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гомуми файдаланыштагы территория – чикләнмәгән даирә затлар бернинди киртәсез файдалана алган территория (шул исәптән мәйданнар, урамнар, юллар, яр буйлары, гомуми файдаланыштагы су объектларының яр буе полосалары, скверлар, бульварлар);»;

1.11. 1 статья:

59 абзацны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Техник регламент – Россия Федерациясенең халыкара килешүе белән кабул ителгән, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә ратификацияләнергә тиешле, яки Россия Федерациясенең халыкара килешүе нигезендә Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә, яки Россия Федерациясе Президенты указы, яки Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, яки федераль башкарма хакимият органының техник көйләү буенча норматив хокукый акты белән ратификацияләнгән һәм техник көйләү объектларына (продукция яки продукциягә һәм продукциягә таләпләр белән бәйле проектлау (тикшеренүне дә исәпкә алып), җитештерү, төзелеш, монтажлау, көйләү, эксплуатацияләү, саклау, күчерү, сату һәм утильләштерү процессларына) файдалану һәм үтәү өчен мәҗбүри булган таләпләрне билгели торган документ;»;

1.12. 1 статья:

62 абзацны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Төзекләндерү элементлары – декоратив, техник, планлаштыру, конструктив җайланмалар, яшелләндерү элементлары, җиһазландыруның һәм бизәүнең төрле төрләре, шул исәптән бина, төзелеш, корылма фасадларын, кече архитектура формалары, капиталь булмаган стационар булмаган төзелешләр һәм корылмалар, территориянең төп төзекләндерү өлеше буларак файдаланылган мәгълүмати щитлар һәм күрсәткечләр;»;

1.13. 11 статья:

үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11 статья. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү тәртибе

1. Гамәлдәге Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 31-33 статьяларында каралган тәртиптә һәм нигездә башкарыла.

2. Гамәлдәге Кагыйдәләргә үзгәрешләр һәм (яки) өстәмәләр кертү җирлек Советы карары белән раслана.

3. Җирлекнең Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы мәсьәләнең каралуы өчен нигез булып тора:

1) җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең җирлекнең генераль планына, шәһәр округы генераль планына, муниципаль районның территориаль

планлаштыру схемасына, әлеге генераль планнарга яки муниципаль районның территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү нәтиҗәсендә барлыкка килгән тәңгәлсезлеге;

1_1) Россия Федерациясе Хөкүмәте белән вәкаләтләндерелгән федераль башкарма хакимият органыннан Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән срокта мәҗбүри рәвештә үтәлергә тиешле җирлек, шәһәр округы, җирлекләр арасындагы территориядә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрендә аэродром буендагы территориядә урнаштырылган күчемсез милек объектларын файдалануга чикләүләрне бозуны бетерү турында күрсәтмә керүе;

2) территориаль зоналарның чикләрен үзгәртү, шәһәр төзелеше регламентларын үзгәртү турында тәкъдимнәр керүе;

3) шәһәр төзелешен зоналарга бүлү картасында күрсәтелгән территорияне аерым шартлар белән файдалану зоналары, мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләренең урнашкан урыннары турында мәгълүматларның Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында теркәлгән әлеге зона, территорияләрнең чикләре урнашкан урын тасвирламасына тәңгәл килмәве;

4) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында теркәлгән аерым шартлар белән файдаланылган территорияләр зонасы, федераль, төбәк һәм җирле әһәмияткә ия истәлекле урыннар территорияләре чигендә тулысынча яки өлешчә урнашкан капиталь төзелеш объектларын һәм җир кишәрлекләрен файдалануда шәһәр төзелеше регламенты белән билгеләнгән чикләүләрнең андый зона, территорияләр чигендә күчемсез милек объектларын файдалануда чикләүләргә тәңгәл килмәве.

5) аерым шартларда файдаланыла торган территория зонасын билгеләү, үзгәртү, бетерү, мәдәни мирас объекты территориясе, федераль әһәмияттәге тарихи җирлек территориясе, төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлек территориясе чикләрен билгеләү, үзгәртү.

4. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәр юнәлдерелә:

1) әгәр җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре федераль әһәмияттәге капиталь төзелеш объектларын урнаштыруга, функцияләштерүгә комачаулык тудыра алган очракта федераль башкарма хакимият органнары тарафыннан;

2) әгәр җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре төбәк әһәмиятендәге капиталь төзелеш объектларын урнаштыруга, функцияләштерүгә комачаулык тудыра алган очракта Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары тарафыннан;

3) әгәр җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре җирле әһәмияттәге капиталь төзелеш объектларын урнаштыруга, функцияләштерүгә комачаулык тудыра алган очракта Буа муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан;

4) әгәр тиешле җирлек территориясендә, шәһәр округы территориясендә, җирлекләр арасындагы территорияләрдә җирдән файдалану һәм төзелешне көйләү кагыйдәләрен камилләштерергә кирәк булган очракта җирле үзидарә органнары тарафыннан;

5) физик һәм юридик затлар тарафыннан инициатива тәртибендә яисә әгәр җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен куллану нәтиҗәсендә җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары нәтиҗәле файдаланылмаса, аларның хокук ияләренә зыян китерелсә, җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш

объектларының хакы төшсә, гражданнарның һәм аларның берләшмәләренең законлы мәнфәгатьләре хокуклары тормышка ашырылмаган очракларда.

5. Комиссия җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында тәкъдим кабул ителгән көннән утыз көн эчендә тәкъдим ителгән үзгәрешләр нигезендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында рекомендацияне үз эченә алган яки кире кагуның сәбәпләрен күрсәтеп, андый тәкъдимне кире кагу турында бәяләмә әзерли, һәм бу бәяләмәне җирлекнең Башкарма комитеты җитәкчесенә юнәлдерә.

6. Җирлекнең Башкарма комитеты җитәкчесе комиссия бәяләмәсендә язылган рекомендацияне исәпкә алып, утыз көн эчендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында яки кире кагуның сәбәпләрен күрсәтеп, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен үзгәртү турында тәкъдимне кире кагу турында карар кабул итә һәм андый карарның күчермәсен гариза бирүчеләргә юнәлдерә.

7. Җирлекнең Башкарма комитеты җитәкчесе җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты турында карар кабул ителгәннән соң ун көннән дә соңармыйча андый карар кабул ителүе турындагы хәбәрнең, муниципаль хокукый актларны “Интернет” челтәрендә рәсми бастырып чыгару өчен билгеләнгән тәртиптә, бастырып чыгарылуын тәэмин итә. Андый карар кабул ителүе турындагы хәбәр шулай ук радио һәм телевидение аша таратыла ала.

7_1. Җирдән файдалану һәм төзелеш тәртипләрен аэродром буендагы территориядә урнаштырылган күчемсез милек объектларын файдалануга чикләүләр белән тәңгәлләштерергә туры килгән очракта җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты турында карар кабул ителүе турында хәбәрне бастыру таләп ителми.

8. Әлеге статьяның 7 өлешендә күрсәтелгән җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү турында карар кабул ителүе хакында хәбәрдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) комиссиянең составы һәм эшчәнлеге тәртибе;

2) җирлек территорияләренә, шәһәр округы яки җирлекләр арасындагы территорияләргә кулланылган яисә җирлек территориясенә яки шәһәр округының төрле өлешләренә кулланылган (җирдән файдалану һәм төзелеш тәртипләре кагыйдәләре проекты әзерләү җирлек һәм шәһәр округы территорияләре өлешләренә кулланылган очракта) шәһәр төзелешен зоналаштыруның эзлеклелеге;

3) җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү буенча эшләрне үткәрү тәртибе һәм сроклары;

4) кызыксынган затларга җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү буенча комиссиягә тәкъдимнәр җибәрү тәртибе;

5) эшләрне оештыруның башка сораулары.

9. Җирлекнең Башкарма комитеты комиссия тәкъдим иткән җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын техник регламентларның таләпләренә, җирлекнең генераль планына, Буа муниципаль районының территориаль планлаштыру схемаларына, Россия Федерациясенең ике һәм аннан күбрәк субъекты территориаль планлаштыру схемаларына, Татарстан Республикасы территориаль планлаштыру схемаларына, Россия Федерациясе территориаль планлаштыру схемаларына тәңгәллеген тикшерүне башкара.

10. Әлеге статьяның 9 өлешендә күрсәтелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча җирлекнең Башкарма комитеты җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре

проектын җирлек башлыгына яки, аның әлеге статьяның 9 өлешендә күрсәтелгән таләпләргә һәм документларга тәңгәл килмәве ачыкланган очракта, комиссиягә эшләп бетерергә җибәрә.

11. Муниципаль берәмлек башлыгы җирлекнең Башкарма комитетыннан җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын алгач, андый проектны алганнан соң ун көннән дә соңармыйча, әлеге проект буенча иҗтимагый фикер алышулар яки ачык тыңлаулар үткәрү турында карар кабул итә.

12. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча иҗтимагый фикер алышулар яки ачык тыңлаулар Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5_1 һәм 28 статьялары һәм әлеге статьяның 13 һәм 14 өлешләре нигезендә җирлек Советының норматив хокукый акты белән билгеләнгән тәртиптә үткәрелә.

13. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча иҗтимагый фикер алышулар яки ачык тыңлауларның дәвамлылыгы андый проект бастырып чыгарылган көннән соң ике айдан азрак һәм дүрт айдан күбрәк тәшкил итми.

14. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә төгәл территориаль зона өчен билгеләнгән шәһәр төзелеше регламентына үзгәрешләр кертү өлешендә үзгәрешләр әзерләнгән очракта, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү буенча иҗтимагый фикер алышулар яки ачык тыңлаулар андый шәһәр төзелеше регламенты билгеләнгән территориаль зона чикләрендә үткәрелә. Бу очракларда иҗтимагый фикер алышулар яки ачык тыңлаулар үткәрү срогы бер айдан да озаграк була алмый.

15. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча иҗтимагый фикер алышулар яки ачык тыңлаулар тәмамланганнан соң комиссия андый иҗтимагый фикер алышулар яки ачык тыңлауларның нәтиҗәләрен исәпкә алып җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектына үзгәрешләр кертүне тәэмин итә һәм әлеге проектны җирле администрация башлыгына тәкъдим итә. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектына, әгәр аларны үткәрү гамәлдәге Кодекс нигезендә таләп ителмәгән очракладан тыш, мәҗбүри рәвештә иҗтимагый фикер алышулар яки ачык тыңлауларның беркетмәсе, иҗтимагый фикер алышулар яки ачык тыңлауларның нәтиҗәләре турында бәяләмә кушымта итеп куела.

16. Җирлекнең Башкарма комитеты җитәкчесе аңа җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты һәм әлеге статьяның 15 өлешендә күрсәтелгән мәҗбүри кушымталар тәкъдим ителгәннән соң ун көн эчендә күрсәтелгән проектны җирлек Советына юнәлдерү турында яки җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын кире кагу һәм аны кабаттан тәкъдим итү датасын күрсәтеп эшләп бетерүгә юнәлдерү турында карар кабул итә.

17. Җирлек Советы җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын һәм аңа мәҗбүри кушымталарны карау нәтиҗәләре буенча җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен расларга яки җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын җирле администрация башлыгына күрсәтелгән проект буенча иҗтимагый фикер алышулар яки ачык тыңлауларның нәтиҗәләре турындагы бәяләмә нигезендә эшләп бетерергә җибәрергә мөмкин.

18. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре муниципаль хокукый актларны рәсми бастыру өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарылырга тиеш.

18.1. Расланган җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре территориаль планлаштыру федераль дәүләт мәгълүмати системасында күрсәтелгән кагыйдәләр расланган датадан ун көннән дә соңармыйча урнаштырылырга тиеш. Әгәр Россия

Федерациясенең Һава кодексы нигезендә билгеләнгән аэродром буендагы территория тулысынча яки өлешчә муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан булса, андый муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы расланган җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре планлаштыру федераль дәүләт мәгълүмати системасында урнаштырылган датадан биш көннән дә соңармыйча Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләтләндергән федераль башкарма хакимият органына электрон формада һәм (яки) почта җибәрүе аша күрсәтелгән кагыйдәләр планлаштыру федераль дәүләт мәгълүмати системасында урнаштырылуы турында хәбәр итә.

19. Физик һәм юридик затлар җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турындагы карарга суд тәртибендә шикаять белдерергә хокуклы.

20. Әлеге статья түбәндәге очракларда кулланылмый:

1) техник үгәрешләр кертелгәндә – орфографик, пунктуация, стилистик хаталарны төзәткәндә;

2) әлеге Кагыйдәләрне федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына, Буа муниципаль районы Уставына, Түбән Наратбаш авыл җирлеге Уставына тәңгәлләштергән очракта.

21. Әлеге статьяның 20 өлеше нигезендә кертелгән үзгәрешләр муниципаль хокукый актларны һәм башка мәгълүматларны рәсми бастыру өчен билгеләнгән тәртиптә мәҗбүри рәвештә бастырылырга тиеш, һәм “Интернет” челтәрендә Түбән Наратбаш авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырыла.

22. Әлеге статья гамәлдәге Кагыйдәләрнең 8 статьясы 5 өлеше нигезләмәләрен исәпкә алып кулланыла.

1.14. 13 статья:

үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13 статья. Җир кишәрлегеннән яки капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү тәртибе

1. Җир кишәрлегеннән яки капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү (алга таба – файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү) тәкъдим ителүендә кызыксынган физик яки юридик зат комиссиягә файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында гариза юнәлдерә.

2. Файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы карар проекты, әлеге статьяның нигезләмәләрен исәпкә алып, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5_1 статьясы белән билгеләнгән тәртиптә үткәрелә торган иҗтимагый фикер алышуларда яки ачык тыңлауларда каралырга тиеш.

3. Әгәр җир кишәрлегеннән яки капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төре әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясарга мөмкин булган очракта, иҗтимагый фикер алышулар яки ачык тыңлаулар андый тискәре йогынты ясалган җир кишәрлеге яки капиталь төзелеш объекты хокук ияләре катнашында үткәрелә.

4. Иҗтимагый фикер алышулар яки ачык тыңлауларны оештыручы файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы карар проекты буенча иҗтимагый фикер алышулар яки ачык тыңлаулар үткәрелүе турында әлеге рөхсәт сорау кулланылган җир кишәрлекләре белән уртак чикләре булган җир кишәрлекләренең хокук ияләренә, әлеге рөхсәт сорау кулланылган җир кишәрлекләре белән уртак чикләре булган җир кишәрлекләрендә урнашкан

капиталь төзелеш объектлары хокук ияләренә, әлеге рөхсәт сорау кулланылган капиталь төзелеш объекты өлеше булган бүлмәләрнең хокук ияләренә хәбәр җибәрә.

7. Иҗтимагый фикер алышулар яки ачык тыңлаулар үткәрүнең, муниципаль берәмлектә яшәүчеләргә аларны үткәрү турында хәбәр бирелгән көннән иҗтимагый фикер алышулар яки ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турындагы бәяләмәне бастыру көненә кадәр срогы җирлек Уставы һәм (яки) җирлек Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә һәм бер айдан да күбрәк була алмый.

8. Файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы карар проекты буенча иҗтимагый фикер алышулар яки ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турындагы бәяләмә нигезендә комиссия файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында яки андый карар кабул итүнең сәбәпләрен күрсәтеп, андый рөхсәт бирүдән баш тарту турында тәкъдимнәр әзерли һәм аларны җирлекнең Башкарма комитеты башлыгына җибәрә.

9. Әлеге статьяның 8 өлешендә күрсәтелгән тәкъдимнәр нигезендә җирле администрация башлыгы андый тәкъдимнәр кергән көннән өч көн эчендә файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында яки андый рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар кабул итә. Әлеге карар муниципаль хокукый актларны һәм башка мәгълүматларны рәсми бастыру өчен билгеләнгән тәртиптә мәҗбүри рәвештә бастырылырга тиеш, һәм “Интернет” челтәрендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында (муниципаль берәмлекнең рәсми сайты булган очракта) урнаштырыла (2005 елның 31 декабрендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законының 2016 елның 1 гыйнварында гамәлгә кергән редакциясендәге өлештә, - элеккеге редакцияне карарга).

10. Файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы карар проекты буенча иҗтимагый фикер алышуларны яки ачык тыңлауларны оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарны андый рөхсәт тәкъдим ителүдә кызыксынган физик яки юридик зат күтәрә.

11. Әгәр файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирүдә кызыксынган физик яки юридик зат тәкъдиме белән иҗтимагый фикер алышулар яки ачык тыңлаулар үткәрелгәннән соң билгеләнгән тәртиптә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү өчен җир кишәрлегеннән яки капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төре шәһәр төзелеше регламентына кертелгән очракта, андый затка файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы карар иҗтимагый фикер алышулар яки ачык тыңлаулар үткәрмичә кабул итә.

11_1. Җирле үзидарә органына дәүләт хакимияте башкарма органыннан, вазыйфаи заттан, дәүләт учреждениесеннән яки җирле үзидарә органыннан гамәлдәге Кодексның 55_32 статьясы 2 өлешендә күрсәтелгән рөхсәтсез төзелеш ачыклануы турында белдерү кергән көннән андый төзелеш урнашкан җир кишәрлегенә карата, яки андый төзелешкә карата аны сүткәнче яки билгеләнгән таләпләргә тәңгәл китерелгәнче, әгәр әлеге белдерүне җирле үзидарә органы карау нәтиҗәсендә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексның 55_32 статьясы 2 өлешендә күрсәтелгән һәм аларда әлеге белдерү кергән дәүләт хакимияте башкарма органына, вазыйфаи затка, дәүләт учреждениесенә яки җирле үзидарә органына рөхсәтсез төзелеш күренешләре булуы ачыкланмавы турында белдерү җибәрелгән яисә рөхсәтсез төзелешне сүтү турында шикаять таләпләрен канәгатьләндерүдән баш тарту яки аны билгеләнгән таләпләргә тәңгәл китерү турында суд карары

законлы көченә кергән очраклардан тыш, файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү тыела.

12. Физик яки юридик зат файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирүне тәкъдим итү яки андый рөхсәтне бирүдән баш тарту турындагы карарга суд тәртибендә шикаять белдерергә хокуклы.

13. Әлеге статья әлеге Кагыйдәләрнең 8 статьясы 5, 6 өлешләре нигезләмәләрен исәпкә алып кулланыла.

1.15. 14 статья:

үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14 статья. Рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын төзекләндерүнең чик параметрларыннан читкә тайпылу

1. Үлчәмнәрне шәһәр төзелеше регламенты белән билгеләнгән җир кишәрлекләренең минималь үлчәменнән азрак булган яисә конфигурациясе, инженер-геологик яки башка характеристикалары төзелеш өчен уңайсыз булган җир кишәрлеге хокук ияләре рөхсәтле төзелешнең, капиталь төзелеш объектын төзекләндерүнең рөхсәт ителгән параметрларыннан тайпылуга рөхсәт белән мөрәҗәгать итәргә мөмкин.

2. Рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын төзекләндерүнең чик параметрларыннан читкә тайпылу техник регламент таләпләрен үтәргәндә аерым җир кишәрлекләре өчен рөхсәт ителә. Рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын төзекләндерүнең чик параметрларыннан бинаның, төзелешнең, корылманың катлары чик саны, чик биеклеге һәм федераль яки төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлек территорияләре чигендә капиталь төзелеш объектларының архитектура чишелешләре таләпләре өлешендә читкә тайпылу рөхсәт ителми.

3. Рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын төзекләндерүнең чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт алуда кызыксынган зат комиссиягә андый рөхсәт бирү турында гариза юллый.

4. Рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын төзекләндерүнең чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү турындагы карар проекты Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексның 39 статьясы нигезләмәләрен исәпкә алып, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексның 5_1 статьясы белән билгеләнгән тәртиптә үткәрелә торган иҗтимагый фикер алышуларда яки ачык тыңлауларда каралырга тиеш. Рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын төзекләндерүнең чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү турындагы карар проекты буенча фикер алышуларны яки ачык тыңлауларны оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарны андый рөхсәт бирүдә кызыксынган физик яки юридик зат күтәрә.

5. Рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын төзекләндерүнең чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү турындагы карар проекты буенча фикер алышулар яки ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә нигезендә комиссия андый рөхсәт бирү яки андый карар кабул итүнең сәбәпләрен күрсәтеп, рөхсәт бирүдән баш тарту турында тәкъдимнәр әзерләүне башкара һәм күрсәтелгән тәкъдимнәрне җирлек Башкарма комитеты җитәкчесенә юллый.

6. Җирлек Башкарма комитеты җитәкчесе әлеге статьяның 5 өлешендә күрсәтелгән тәкъдимнәр кергәннән соң җиде көн эчендә рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын төзекләндерүнең чик параметрларыннан читкә

тайпылуга рөхсәт бирү турында яки андый карар кабул итүнең сәбәпләрен күрсәтеп, рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар чыгара.

6_1. Җирле үзидарә органына дәүләт хакимияте башкарма органыннан, вазыйфаи заттан, дәүләт учреждениесеннән яки җирле үзидарә органыннан гамәлдәге Кодексның 55_32 статьясы 2 өлешендә күрсәтелгән рөхсәтсез төзелеш ачыклануы турында белдерү кергән көннән андый төзелеш урнашкан җир кишәрлегенә карата, яки андый төзелешкә карата аны сүткәнче яки билгеләнгән таләпләргә тәңгәл китерелгәнче, әгәр әлеге белдерүне җирле үзидарә органы карау нәтиҗәсендә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексның 55_32 статьясы 2 өлешендә күрсәтелгән һәм аларда әлеге белдерү кергән дәүләт хакимияте башкарма органына, вазыйфаи затка, дәүләт учреждениесенә яки җирле үзидарә органына рөхсәтсез төзелеш күренешләре булуы ачыкланмавы турында белдерү җибәрелгән яисә рөхсәтсез төзелешне сүтү турында шикаять таләпләрен канәгатьләндерүдән баш тарту яки аны билгеләнгән таләпләргә тәңгәл китерү турында суд карары законлы көченә кергән очраклардан тыш, рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын төзекләндерүнең чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү тыела.

7. Физик яки юридик зат рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын төзекләндерүнең чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирүне тәкъдим итү яки андый рөхсәтне бирүдән баш тарту турындагы карарга суд тәртибендә шикаять белдерергә хокуклы.

8. Рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын төзекләндерүнең чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү, әгәр андый тайпылыш аэродром буендагы территориядә урнашкан күчемсез милек объктларын файдалануга чикләүләргә тәңгәл килмәгәндә тыела.

1.16. 16 статья:

2 пунктны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Җир кишәрлекләренең шәһәр төзелеше планнары составы Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексның 57.3 статьясы белән билгеләнгән.»;

1.17. VI бүлек:

үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«VI БҮЛЕК. Ачык тыңлаулар

17 статья. Генераль планнар проектлары, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектлары, территорияне планировкалау проектлары, территорияне межалау проектлары, территорияне төзекләндерү кагыйдәләре проектлары, файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирүне тәкъдим итү турында карарларның проектлары, рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын төзекләндерүнең чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү турында карарларның проектлары буенча иҗтимагый фикер алышулар, ачык тыңлаулар

1. Кешенең уңайлы тормыш алып баруга хокукын, генераль планнар проектлары, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектлары, территорияне планировкалау проектлары, территорияне межалау проектлары, территорияне төзекләндерү кагыйдәләре проектлары, күрсәтелгән расланган документларның берсенә үзгәрешләр кертүне күзаллаган проектлары, файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирүне тәкъдим итү турында карарларның проектлары,

рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын төзекләндерүнең чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү турында карарларның проектлары (алга таба әлеге статьяда шулай ук – проектлар) буенча хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатында муниципаль берәмлек Уставы һәм (яки) Җирлек Советының норматив хокукый акты нигезендә һәм Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезләмәләрен исәпкә алып, гамәлдәге Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы һәм башка федераль законнарда каралган очраклардан тыш, иҗтимагый фикер алышулар һәм ачык тыңлаулар үткәрелә.

2. Ачык тыңлаулар Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, муниципаль берәмлек Уставы, Буа муниципаль районы Түбән Наратбаш авыл җирлегендә ачык тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә, әлеге Кагыйдәләр нигезендә үткәрелә.

3. Җирдән файдалану һәм төзелеш мәсьәләләре буенча ачык тыңлауларга чыгарыла:

Түбән Наратбаш авыл җирлеге генераль планы проекты;

Кагыйдәләр проекты, әлеге Кагыйдәләргә үзгәрешләр һәм (яки) өстәмәләр кертү проекты;

территорияне планировкалау проекты;

территорияне межалау проекты;

җир кишәрлегеннән яки капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирүне тәкъдим итү турында карарлар проекты;

рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын төзекләндерүнең чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү турында карарлар проекты.

4. Әлеге статьяның 3 өлешендә күрсәтелгән мәсьәләләр буенча ачык тыңлаулар, иҗтимагый фикер алышулар, генераль планны раслау һәм аңа үзгәрешләр кертү мәсьәләләре буенча ачык тыңлаулардан тыш, Түбән Наратбаш авыл җирлеге башлыгы карары буенча Комиссия тарафыннан үткәрелә.

5. Генераль планны раслау һәм аңа үзгәрешләр кертү мәсьәләләре буенча ачык тыңлаулар Түбән Наратбаш авыл җирлеге башлыгы карары буенча җирлекнең Башкарма комитеты тарафыннан үткәрелә.

6. Ачык тыңлаулар, иҗтимагый фикер алышулар билгеләнүе турындагы хәбәрнең эчтәлегендә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) ачык тыңлауларда яки иҗтимагый фикер алышуларда каралырга тиешле проект турында мәгълүмат һәм андый проектка мәгълүмати материаллар исемлеге;

2) ачык тыңлауларда яки иҗтимагый фикер алышуларда каралырга тиешле проект буенча ачык тыңлаулар яки иҗтимагый фикер алышулар үткәрү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат;

3) ачык тыңлауларда яки иҗтимагый фикер алышуларда каралырга тиешле проектның экспозициясе яки экспозицияләре ачылу урыны, датасы, андый проектның экспозициясен яки экспозицияләрен үткәрү сроклары, әлеге экспозицияне яки экспозицияләрне килеп карау мөмкин булган көннәр һәм сәгатьләр турында мәгълүмат;

4) ачык тыңлауларда яки иҗтимагый фикер алышуларда катнашучыларның ачык тыңлауларда яки иҗтимагый фикер алышуларда каралырга тиешле проектка кагылышлы тәкъдимнәрен һәм искәрмәләрен кертү тәртибе, срогы һәм формасы турында мәгълүмат.

Иҗтимагый фикер алышулар башлануы турындагы хәбәрдә шулай ук иҗтимагый фикер алышуда каралырга тиешле проект, һәм аңа мәгълүмати

материаллар урнаштырылачак рәсми сайт, яки иҗтимагый фикер алышулар аларны файдаланып үткәреләчәк әлеге проект һәм аңа мәгълүмати материаллар урнаштырылачак мәгълүми системалар турында мәгълүмат булырга тиеш. Ачык тыңлаулар турындагы хәбәрдә шулай ук ачык тыңлауларда каралырга тиешле проект, һәм аңа мәгълүмати материаллар урнаштырылачак рәсми сайт турында мәгълүмат, ачык тыңлауларда катнашучыларның җыелышы яки җыелышлары датасы, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат булырга тиеш.

7. Иҗтимагый фикер алышулар яки ачык тыңлаулар башлануы турында хәбәр:

1) Иҗтимагый фикер алышуларда яки ачык тыңлауларда каралырга тиешле проект рәсми сайтта яки мәгълүмати системаларда урнаштырылган көннән җиде көннән дә соңармыйча муниципаль хокукый актларны, башка рәсми мәгълүматны рәсми бастыру өчен билгеләнгән тәртиптә, әгәр бу муниципаль хокукый актларда каралган булса, башка гаммәви мәгълүмат чараларында бастырылырга тиеш;

2) иҗтимагый фикер алышулар яки ачык тыңлаулар үткәрүгә вәкаләтле җирле үзидарә органы биналары янында корып куелган мәгълүмат стендларында, кешеләр күп була торган урыннарда һәм аңа карата тиешле проектлар әзерләнгән территориядә урнашкан башка урыннарда, һәм (яки) әлеге статьяның 3 өлешендә күрсәтелгән территориаль зоналар һәм (яки) җир кишәрлекләре (алга таба – чикләрендә иҗтимагый фикер алышулар яки ачык тыңлаулар үткәрелә торган территория) чикләрендә, иҗтимагый фикер алышуларда яки ачык тыңлауларда катнашучыларга күрсәтелгән мәгълүматка үтеп керүне тәэмин итүче башка ысуллар белән таратыла.

8. Проект буенча иҗтимагый фикер алышулар яки ачык тыңлаулар билгеләнүе турындагы карардан тыш, ачык тыңлаулар предметы турында кыскача мәгълүмати записка һәм график материаллар бастырып чыгарылырга (халыкка белдерелергә) тиеш.

9. Ачык тыңлаулар яки иҗтимагый фикер алышулар үткәрү турында карар бастырып чыгарылган көннән аларны үткәргән көнгә кадәр җирлек халкы ачык тыңлауга чыгарылган мәсьәлә буенча язмача тәкъдимнәрен һәм искәрмәләрен юнәлдерергә хокуклы. Комиссия кергән тәкъдим һәм искәрмәләрне гомумиләштерүне оештыра. Әлеге тәкъдимнәр һәм күрсәтмәләр ачык тыңлауларда катнашучылар игътибарына җиткерелә.

10. Фикер алышулар башланыр алдыннан ачык тыңлауларда яки иҗтимагый фикер алышуларда катнашучыларга мәгълүмат бирелергә тиеш:

фикер алышуның дәвамлылыгы турында;

ачык тыңлаулар яки иҗтимагый фикер алышулар үткәрү регламенты турында (ачык тыңлауларда катнашучылар чыгышларының дәвамлылыгы чиге мәсьәләләрен дә исәпкә алып);

ачык тыңлауларның предметы турында.

11. Ачык тыңлаулар яки иҗтимагый фикер алышулар үткәрү барышында беркетмә алып барыла. Беркетмәдә ачык тыңлаулар предметына кагылышлы, ачык тыңлауларда катнашучылардан телдән һәм язмача кергән искәрмәләр һәм тәкъдимнәр теркәлә.

12. Беркетмә нигезләмәсен исәпкә алып ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү башкарыла.

13. Ачык тыңлаулар яки иҗтимагый фикер алышулар нәтиҗәләре турында бәяләмә муниципаль хокукый актларны, башка рәсми мәгълүматны рәсми бастыру

өчен билгеләнгән тәртиптә ачык тыңлаулар үткәрелгән көннән биш көннән дә соңармаган срокта бастырылырга тиеш.

14. Ачык тыңлауларда яки иҗтимагый фикер алышуларда катнашучыларның фикерләре ачыклануы ачык тыңлаулар нәтиҗәләрен исәпкә алып карар кабул итүче органны ачык тыңлауларда катнашучыларның фикерен чагылдырган карар кабул итәргә мәҗбүр итҗми.

15. Әлеге статья әлеге Кагыйдәнең 8 статьясы 5 өлеше нигезләмәләрен исәпкә алып кулланыла.

18 статья. Түбән Наратбаш авыл җирлеге генераль планы проекты, аңа үзгәрешләр кертү проектлары буенча ачык тыңлаулар үткәрү үзенчәлекләре

1. Җирлекнең генераль планы проекты һәм җирлекнең генераль планына үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проект буенча ачык тыңлаулар яки иҗтимагый фикер алышулар (алга таба – иҗтимагый фикер алышулар яки ачык тыңлаулар) Җирлекнең һәр торак пунктында үткәрелә.

2. Ачык тыңлаулар яки иҗтимагый фикер алышулар үткәргәндә ачык тыңлаулар яки иҗтимагый фикер алышуларда катнашучыларның ачык тыңлаулар яки иҗтимагый фикер алышуларда катнашу өчен тигез мөмкинлекләр белән тәэмин итү максатларында торак пункт территориясе өч өлешкә бүленергә мөмкин.

3. Ачык тыңлаулар яки иҗтимагый фикер алышулар үткәрүнең муниципаль берәмлектә яшәүчеләргә аларның үткәрелүе турында хәбәр ителү вакытыннан алып ачык тыңлаулар яки иҗтимагый фикер алышулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне бастырып чыгару көненә кадәр срогы җирлекнең уставы һәм (яки) җирлек Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә һәм бер айдан азрак һәм өч айдан күбрәк була алмый.

4. Җирлекнең Башкарма комитеты җитәкчесе ачык тыңлаулар яки иҗтимагый фикер алышулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне исәпкә алып карар кабул итә:

1) генраль план проекты белән килешү һәм аны муниципаль берәмлекнең вәкаләтле органына юнәлдерү турында;

2) генераль план проектын кире кагу турында һәм аны эшләп бетерергә юнәлдерү турында.

4. Әлеге статья әлеге Кагыйдәләрнең 8 статьясы 5 өлеше нигезләмәләрен исәпкә алып кулланыла.

19 статья. Территорияне планлаштыру проектлары һәм территорияне межалау проектлары буенча ачык тыңлаулар үткәрү үзенчәлекләре

1. Җирлек территориясенә, шәһәр округы территориясенә кулланылучы территорияне планлаштыру буенча документларны әзерләү турындагы карар, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45 статьясы 2-4_2 һәм 5_2 өлешләрендә күрсәтелгән очраклардан тыш, җирлекнең Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелгән орган тәкъдиме белән яисә физик яки юридик затларның территорияне планлаштыру буенча документлар әзерләү турындагы тәкъдимнәре буенча кабул ителә. Территорияне планлаштыру буенча документларны әзерләү Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45 статьясы 1_1 өлешендә күрсәтелгән кызыксынган затлар тарафыннан башкарылган булса, җирлекнең Башкарма комитетына территорияне планлаштыру буенча документларны әзерләү турында карар чыгару таләп ителми.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән карар муниципаль хокукый актларны, башка рәсми мәгълүматларны рәсми бастыру өчен Уставта каралган тәртиптә андый карар кабул ителгән көннән өч көн эчендә бастырып чыгарылырга тиеш.

3. Территорияне планлаштыру буенча документларны әзерләү буенча карар бастырып чыгарылган көннән физик яки юридик затлар җирлекнең Башкарма комитетына территорияне планлаштыру буенча документларның тәртибе, әзерләү сроклары һәм эчтәлеге турында үз тәкъдимнәрен кертергә хокуклы.

3_1. Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45 статьясы 1_1 өлешендә күрсәтелгән кызыксынган затлар территорияне планлаштыру буенча документларны Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45 статьясы 10 өлешендә күрсәтелгән таләпләр нигезендә әзерли, һәм аны раслату өчен җирлекнең Башкарма комитетына юнәлдерә.

4. Җирлекнең Башкарма комитеты территорияне планлаштыру буенча документларның Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45 статьясы 10 өлешендә күрсәтелгән таләпләргә тәңгәл килүен тикшерүне башкара. Тикшерү нәтиҗәләре буенча күрсәтелгән орган территорияне планлаштыру буенча документларны җирлек башлыгына юнәлдерү яки андый документларны кире кагу һәм аны эшләп бетерергә җибәрү турында тиешле карар кабул итә.

5. Аларны раслау турындагы карарны җирлекнең Башкарма комитеты тарафыннан кабул ителгән территорияне планлаштыру проектлары, территорияне межалау проектлары, аларны раслау алдыннан мәҗбүри рәвештә иҗтимагый фикер алышуларда яки ачык тыңлауларда каралырга тиеш.

5_1. Территорияне планлаштыру проектлары, территорияне межалау проектлары буенча иҗтимагый фикер алышулар яки ачык тыңлаулар, әгәр алар түбәндәгеләргә карата әзерләнгән булса, үткәрелми:

1) чикләрендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре нигезендә территорияне комплекслы һәм тотрыклы үстерү буенча эшчәнлек алып бару каралган территориягә;

2) бакчачылык, яшелчәчелек, дача хуҗалыгы яки дача хуҗалыгын алып бару өчен яки юридик затларга дача хуҗалыгын алып бару өчен гражданнар тарафыннан оештырылган коммерцияле булмаган оешмага тәкъдим ителгән җир кишәрлеге чикләрендәге территориягә;

3) урман фонды җирләре чикләрендәге линия объектларын урнаштыру өчен территориягә.

6. Территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне межалау проекты буенча иҗтимагый фикер алышулар һәм ачык тыңлаулар Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5_1 статьясы белән билгеләнгән тәртиптә, әлеге статьяның нигезләмәләрен исәпкә алып үткәрелә.

7. Җирлекнең Башкарма комитеты тиешенчә җирлекнең Башкарма комитеты җитәкчесенә территорияне планлаштыру буенча әзерләнгән документларны, территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне межалау проекты буенча иҗтимагый фикер алышулар һәм ачык тыңлаулар беркетмәсен, иҗтимагый фикер алышулар һәм ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне иҗтимагый фикер алышулар һәм ачык тыңлаулар үткәрелгән көннән унбиш көннән дә соңармыйча юнәлдерә.

8. Җирлекнең Башкарма комитеты җитәкчесе территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне межалау проекты буенча иҗтимагый фикер алышулар

һәм ачык тыңлаулар беркетмәсен һәм иҗтимагый фикер алышулар һәм ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне исәпкә алып, территорияне планлаштыру буенча документларны раслау турында яки андый документларны кире кагу турында һәм аны җирлекнең Башкарма комитетына күрсәтелгән беркетмә һәм бәяләмәләрне исәпкә алып эшләп бетерергә юнәлдерү турында карар чыгара.

9. Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45 статьясы 1_1 өлешендә күрсәтелгән затлар белән әзерләнгән территорияне планлаштыру буенча документларны кире кагу, һәм аны эшләп бетерүгә юнәлдерү өчен нигез булып, андый документларның Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45 статьясы 10 өлешендә күрсәтелгән таләпләргә җавап бирмәве тора. Башка очракларда андый затлар тарафыннан тәкъдим ителгән территорияне планлаштыру буенча документларны кире кагу рөхсәт ителми.

10. Территорияне планлаштыру буенча расланган документлар (территорияне планлаштыру проектлары һәм территорияне межалау проектлары) җирлекнең Уставы белән билгеләнгән муниципаль хокукый актларны, башка рәсми мәгълүматларны рәсми бастырып чыгару тәртибендә, күрсәтелгән документлар расланган көннән җиде көн эчендә бастырып чыгарылырга тиеш.

11. Җирлекләр арасындагы территорияне планлаштыру буенча документлар Буа муниципаль районы Башкарма комитеты карарына таянып, әлеге статья таләпләре нигезендә әзерләнә.

20 статья. Кагыйдәләр проекты, Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү проектлары буенча ачык тыңлаулар үткәрү үзченчәлекләре

1. Территорияне төзекләндерү кагыйдәләре проекты буенча иҗтимагый фикер алышулар яки ачык тыңлаулар үткәрүнең иҗтимагый фикер алышулар яки ачык тыңлаулар башлану турында хәбәрне бастырган көннән иҗтимагый фикер алышулар яки ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне бастыру көненә кадәр срогы җирлекнең Уставы һәм (яки) җирлек Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә һәм бер айдан азрак һәм өч айдан күбрәк була алмый.

2. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектлары һәм җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проект буенча иҗтимагый фикер алышуларда яки ачык тыңлауларда катнашучылар булып, әлеге проектлар аларга карата әзерләнгән территориядә даими яшәүче гражданнар, әлеге территория чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләре һәм (яки) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларының хокук ияләре, һәм шулай ук күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының өлеше булган бүлмәләрнең хокук ияләре тора.

21 статья. Җир кишәрлегеннән яки капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү мәсьәләләре буенча ачык тыңлаулар үткәрү

Җир кишәрлегеннән яки капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында карар проекты, рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын төзекләндерүнең чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү турында карар проекты буенча иҗтимагый фикер алышуларда яки ачык тыңлауларда катнашучылар булып, аларга карата әлеге проектлар әзерләнгән җир кишәрлеге яки капиталь төзелеш объекты урнашкан территориаль зона чикләрендә даими яшәүче гражданнар, әлеге

территораль зона чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләре һәм (яки) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектлары хокук ияләре, аларга карата әлеге проектлар әзерләнгән җир кишәрлекләренә янәшәдәге җир кишәрлекләре чикләрендә даими яшәүче гражданнар, андый җир кишәрлекләренең яки аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларының хокук ияләре, аларга карата әлеге проектлар әзерләнгән капиталь төзелеш объектының өлеше булган бүлмәләрнең хокук ияләре, ә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексның 39 статьясы 3 өлешендә каралган очракларда, шулай ук әлеге проектларны тормышка ашыру нәтиҗәсендә әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясау куркынычы булган капиталь төзелеш объектлары һәм җир кишәрлекләре хокук ияләре тора.

Җир кишәрлегеннән яки капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирүдә (алга таба – файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү) кызыксынган физик яки юридик зат комиссиягә файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирүне тәкъдим итү турында гариза юнәлдерә.

2. Файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирүне тәкъдим итү турында карар проекты иҗтимагый фикер алышуларда яки ачык тыңлауларда каралырга тиеш.

3. Әгәр җир кишәрлегеннән яки капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төре әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясарга мөмкин булган очракта, иҗтимагый фикер алышулар яки ачык тыңлаулар андый тискәре йогынты ясалган җир кишәрлеге яки капиталь төзелеш объекты хокук ияләре катнашында үткәрелә.

4. Иҗтимагый фикер алышулар яки ачык тыңлауларны оештыручы файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы карар проекты буенча иҗтимагый фикер алышулар яки ачык тыңлаулар үткәрелүе турында әлеге рөхсәт сорау кулланылган җир кишәрлекләре белән уртак чикләре булган җир кишәрлекләренең хокук ияләренә, әлеге рөхсәт сорау кулланылган җир кишәрлекләре белән уртак чикләре булган җир кишәрлекләрендә урнашкан капиталь төзелеш объектлары хокук ияләренә, әлеге рөхсәт сорау кулланылган капиталь төзелеш объекты өлеше булган бүлмәләрнең хокук ияләренә хәбәр җибәрә. Әлеге хәбәрләр кызыксынган заттан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирүне тәкъдим итү турында гариза кергәннән соң ун көннән дә соңармыйча юнәлдерелә.

7. Иҗтимагый фикер алышулар яки ачык тыңлаулар үткәрүнең, муниципаль берәмлектә яшәүчеләргә аларны үткәрү турында хәбәр бирелгән көннән иҗтимагый фикер алышулар яки ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турындагы бәяләмәне бастыру көненә кадәр срогы җирлек Уставы һәм (яки) җирлек Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә һәм бер айдан да күбрәк була алмый.

8. Файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы карар проекты буенча иҗтимагый фикер алышулар яки ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турындагы бәяләмә нигезендә комиссия файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында яки андый карар кабул итүнең сәбәпләрен күрсәтеп, андый рөхсәт бирүдән баш тарту турында тәкъдимнәр әзерли һәм аларны җирлекнең Башкарма комитеты башлыгына җибәрә.

9. Әлеге статьяның 8 өлешендә күрсәтелгән тәкъдимнәр нигезендә җирлекнең Башкарма комитеты җитәкчесе андый тәкъдимнәр кергән көннән өч көн эчендә файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында яки андый

рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар кабул итә. Әлеге карар муниципаль хокукый актларны бастыру өчен җирлек Уставы билгеләгән тәртиптә бастырылырга тиеш.

10. Файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы карар проекты буенча иҗтимагый фикер алышуларны яки ачык тыңлауларны оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарны андый рөхсәт тәкъдим ителүдә кызыксынган физик яки юридик зат күтәрә.

11. Әгәр файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирүдә кызыксынган физик яки юридик зат тәкъдиме белән иҗтимагый фикер алышулар яки ачык тыңлаулар үткәрелгәннән соң билгеләнгән тәртиптә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү өчен җир кишәрлегеннән яки капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төре шәһәр төзелеше регламентына кертелгән очракта, андый затка файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы карар иҗтимагый фикер алышулар яки ачык тыңлаулар үткәрмичә кабул итә.

11_1. Җирле үзидарә органына дәүләт хакимияте башкарма органыннан, вазыйфаи заттан, дәүләт учреждениесеннән яки җирле үзидарә органыннан гамәлдәге Кодексның 55_32 статьясы 2 өлешендә күрсәтелгән рөхсәтсез төзелеш ачыклануы турында белдерү кергән көннән андый төзелеш урнашкан җир кишәрлегенә карата, яки андый төзелешкә карата аны сүткәнче яки билгеләнгән таләпләргә тәңгәл китерелгәнче, әгәр әлеге белдерүне җирле үзидарә органы карау нәтиҗәсендә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексның 55_32 статьясы 2 өлешендә күрсәтелгән һәм аларда әлеге белдерү кергән дәүләт хакимияте башкарма органына, вазыйфаи затка, дәүләт учреждениесенә яки җирле үзидарә органына рөхсәтсез төзелеш күренешләре булуы ачыкланмавы турында белдерү җибәрелгән яисә рөхсәтсез төзелешне сүтү турында шикаять таләпләрен канәгатьләндерүдән баш тарту яки аны билгеләнгән таләпләргә тәңгәл китерү турында суд карары законлы көченә кергән очраклардан тыш,  файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү тыела.

12. Физик яки юридик зат файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирүне тәкъдим итү яки андый рөхсәтне бирүдән баш тарту турындагы карарга суд тәртибендә шикаять белдерергә хокуклы.

13. Ачык тыңлаулар үткәрүнең аларны үткәрү вакыты һәм урыны турында хәбәр биргәннән соң ачык тыңлауларның нәтиҗәләре турында бәяләмәне бастырып чыгарган көнгә кадәр срогы бер айдан күбрәк була алмый.

14. Рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча ачык тыңлауларны оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарны кызыксынган зат күтәрә.

22.1 статья. Рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын төзекләндерүнең чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт тәкъдим итү

4. Рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын төзекләндерүнең чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү турындагы карар проекты Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексның 39 статьясы нигезләмәләрен исәпкә алып, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексның 5_1 статьясы белән билгеләнгән тәртиптә үткәрелә торган  иҗтимагый фикер алышуларда яки ачык тыңлауларда каралырга тиеш. Рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын төзекләндерүнең чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү

турындагы карар проекты буенча фикер алышуларны яки ачык тыңлауларны оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарны андый рөхсәт бирүдә кызыксынган физик яки юридик зат күтәрә.

5. Рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын төзекләндерүнең чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү турындагы карар проекты буенча фикер алышулар яки ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә нигезендә комиссия андый рөхсәт бирү яки андый карар кабул итүнең сәбәпләрен күрсәтеп, рөхсәт бирүдән баш тарту турында тәкъдимнәр әзерләүне башкара һәм күрсәтелгән тәкъдимнәрне җирлек Башкарма комитеты җитәкчесенә юллый.

6. Җирлек Башкарма комитеты җитәкчесе әлеге статьяның 5 өлешендә күрсәтелгән тәкъдимнәр кергәннән соң җиде көн эчендә рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын төзекләндерүнең чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү турында яки андый карар кабул итүнең сәбәпләрен күрсәтеп, рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар чыгара.

6_1. Җирле үзидарә органына дәүләт хакимияте башкарма органыннан, вазыйфаи заттан, дәүләт учреждениесеннән яки җирле үзидарә органыннан гамәлдәге Кодексның 55_32 статьясы 2 өлешендә күрсәтелгән рөхсәтсез төзелеш ачыклануы турында белдерү кергән көннән андый төзелеш урнашкан җир кишәрлегенә карата, яки андый төзелешкә карата аны сүткәнче яки билгеләнгән таләпләргә тәңгәл китерелгәнче, әгәр әлеге белдерүне җирле үзидарә органы карау нәтиҗәсендә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексның 55_32 статьясы 2 өлешендә күрсәтелгән һәм аларда әлеге белдерү кергән дәүләт хакимияте башкарма органына, вазыйфаи затка, дәүләт учреждениесенә яки җирле үзидарә органына рөхсәтсез төзелеш күренешләре булуы ачыкланмавы турында белдерү җибәрелгән яисә рөхсәтсез төзелешне сүтү турында шикаять таләпләрен канәгатьләндерүдән баш тарту яки аны билгеләнгән таләпләргә тәңгәл китерү турында суд карары законлы көченә кергән очраклардан тыш, рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын төзекләндерүнең чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү тыела.

7. Физик яки юридик зат рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын төзекләндерүнең чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирүне тәкъдим итү яки андый рөхсәтне бирүдән баш тарту турындагы карарга суд тәртибендә шикаять белдерергә хокуклы.

8. Рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын төзекләндерүнең чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү, әгәр андый тайпылыш аэродром буендагы территориядә урнашкан күчемсез милек объктларын файдалануга чикләүләргә тәңгәл килмәгәндә тыела.

1.18. VII Бүлек:

үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«VII БҮЛЕК. Капиталь төзелеш объектларының үзгәртеп корылуы

Статья 22. Капиталь төзелеш объектларын үзгәртеп кору хокукы. Капиталь төзелеш объектларын үзгәртеп кору төрләре

1. Җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары хокук ияләре, аларның ышанычлы затлары капиталь төзелеш объектларын үзгәртеп коруны башкарырга хокуклы. Капиталь төзелеш объектын үзгәртеп кору дигәндә яңа төзелеш, төзекләндерү, янкорма(лар) төзү, капиталь төзелеш объектын сүтү, капиталь төзелеш объектының конструктив һәм ышанычлыгына һәм куркынычсызлыгы

характеристикаларына кагыла торган капиталь ремонт, капиталь төзелеш объектының бүтән шундый үзгәрешләре аңлашыла.

Капиталь төзелеш объектларын үзгәртеп коруга хокук шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә тәкъдим ителүче, әлеге статьяның 2 өлешендә билгеләнгән очраклардан тыш, төзелешкә рөхсәт булганда гына гамәлгә ашырыла ала.

2. Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексның 51 статьясы нигезендә төзелешкә рөхсәт бирү түбәндәге очракларда таләп ителми:

1) физик затка эшмәкәрлек эшчәнлеге белән бәйле булмаган максатларда бирелгән җир кишәрлегендә гараж төзү, төзекләндерү яки бакча җир кишәрлегендә торак йортны, бакча йортын, хуҗалык корылмаларын төзү, төзекләндерү;

1.1) шәхси торак төзелеше объектларын төзү, төзекләндерү;

2) капиталь төзелеш объекты булмаган объектларны төзү, төзекләндерү;

3) җир участогында ярдәмче файдаланылыштагы төзелешләр һәм корылмалар төзү;

4) капитальтөзелеш объектларының һәм аларның өлешләрен үзгәртү, әгәр андый үзгәрешләр аларның конструктив һәм башка ышанычлылыгы һәм иминлеге характеристикаларына кагылмаса һәм шәһәр төзелеше регламенты белән билгеләнгән рөхсәт ителгән төзелешнең, төзекләндерүнең чик параметрларыннан артмаса;

4.1) капиталь төзелеш объектларын капиталь ремонтлау;

4.2) җир асты байлыклары турында Россия Федерациясе законнары нигезендә әзерләнгән, килешенгән һәм расланган файдалы казылма ятмаларын эшкәртүнең техник проекты белән яки җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга бәйле эшләрне башкаруга башка проект документлары белән каралган бораулау скважиналарын төзү, реконструкцияләү;

4.3) Россия Федерациясенең чит илләрдәге илчелеген, консуллыгын һәм вәкиллеген төзү, төзекләндерү;

4.4) 0,6 мегапаскальгә кадәр басым астында табигый газны транспортлау өчен билгеләнгән объектларны төзү, төзекләндерү;

5) Гамәлдәге кодекс, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актлары, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында Россия Федерациясе субъектының законнары нигезендә төзелешкә рөхсәт алу таләп ителмәгән башка очракларда.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 24 июнендәге 1038-р номерлы карары белән, аларга төзелешкә рөхсәт алу таләп ителмәгән, өстәмә очраклар һәм объектлар исемлеге билгеләнгән:

гараж, әгәр андый төзелеш өчен җир кишәрлеге гараж-төзелеш кооперативына тәкъдим ителгән җир кишәрлеге составында урнашкан булса;

физик затка эшмәкәрлек эшчәнлеген башкару белән бәйле булмаган максатларда тәкъдим ителгән җир кишәрлегендәге, шәхси торак төзелеше объектларыннан тыш, төзелешләр һәм корылмалар;

аларны төзү һәм (яки) үзгәртеп кору технологик тотыштырып һәм (яки) Татарстан Республикасының территориаль газ бүлү оешмалары белән килештерелгән инвестиция программаларын башкарып, шул исәптән шәхси торак йортлар һәм күпфатирлы йортлар төзелгән торак төзелеше зоналарында федераль, республика дәүләт программаларында карала торган газ бүлү челтәрләре, шул исәптән шкаф, блок тибындагы газны җайга сала торган пунктлар һәм электрохимик саклау җайланмалары;

аларны төзү һәм (яки) үзгәртеп кору технологик тоташтырып һәм/яки территориаль челтәр оешмасының инвестиция программасын үтәп карала торган, электртапшыру линияләрен (ВЛ, КЛ) дә кертеп, электр челтәрләре хуҗалыгы объектлары, шәхси торак йортлар һәм күпфатирлы йортлар төзелгән торак төзелеше зоналарындагы 0,4-20 кВ көчәнеш класслы трансформатор подстанцияләре;

аларны төзү һәм (яки) төзекләндерү федераль һәм (яки) республика һәм/яки инвестицион программалар белән каралган һәм (яки) шәхси торак йортлар һәм күпфатирлы йортлар төзелгән торак төзелешләр зонасында дәүләт казна учреждениеләре белән башкарылган, инженерлык инфраструктурасының бүлү челтәрләре, аның белән технологик яктан бәйләнешле җайланмалар һәм корылмалар, аларны төзү һәм (яки) төзекләндерү Казан шәһәрендә метрополитен төзү кысаларында башкарылган инженерлык инфраструктурасының бүлү челтәрләре, аның белән технологик яктан бәйләнешле җайланмалар һәм корылмалар, шулай ук аларны төзү һәм (яки) төзекләндерү “Россия Федерациясе гражданнарын үтемле һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү” Россия Федерациясе дәүләт программасы кысаларында “Россия гаиләсе өчен торак” программасын тормышка ашыру кысаларында гамәлгә ашырылган инженерлык инфраструктурасының бүлү челтәрләре, аның белән технологик яктан бәйләнешле җайланмалар һәм корылмалар;

җир астыннан салынган җылылык челтәрләре, алар белән техник яктан бәйләнештәге җайланмалар һәм корылмалар;

аларны төзү һәм (яки) төзекләндерү федераль һәм (яки) республика һәм (яки) инвестиция программалары һәм (яки) федераль һәм республика программаларын тормышка ашыру максатларында шәһәр округы, җирлек чикләрендә башкарылган салкын су белән тәэмин ителеш, җир астыннан салынган юынтык суларны агызу челтәрләре, аның белән технологик яктан бәйләнештәге җайланмалар һәм корылмалар;

50 метрга кадәр биеклектәге элемтә антенна-мачта корылмалары, законнар белән аеруча куркыныч, техник яктан катлаулы яки уникаль объктларга кертелгән элемтә корылмаларыннан тыш;

элемтә линия-кабель корылмалары, законнар белән аеруча куркыныч, техник яктан катлаулы яки уникаль объктларга кертелгән элемтә корылмаларыннан тыш, шул исәптән аларны төзекләндергәндә;

автомобиль юллары, аларны төзү һәм (яки) төзекләндерү федераль һәм/яки республика программалары белән каралган һәм дәүләт муниципаль казна учреждениеләре белән аларның төзелеше территорияне планировкалау буенча расланган документлар белән тәэмин ителгән Татарстан Республикасы гражданнарын социаль ипотека системасы территорияләрендә торак белән тәэмин итү максатында башкарылган шәхси торак йортлар һәм күпфатирлы йортлар төзелгән торак зонада башкарылган.

Төзелешкә рөхсәт таләп итми торган гамәлләр башкарган затлар андый гамәлләрне башкару нәтиҗәсендә килеп чыккан нәтиҗәләр өчен законнар нигезендә җаваплылык тота.

23 статья. Проект документларын әзерләү

1. Проект документларын билгеләү, составы, эчтәлеге, әзерләү тәртибе һәм раслануы шәһәр төзелеше турындагы законнар һәм башка норматив хокукый актлар белән билгеләнә.

Россия Федерациясе Шәһәр кодексының 48 статьясы 3 өлеше нигезендә проект документларын әзерләү шәхси торак төзелеше, бакча йорты төзелеше һәм төзекләндерүе вакытында таләп ителми. Төзүчн үз теләге белән шәхси торак төзелеше объектына, бакча йортына кулланылган проект документларын әзерләүнне тәэмин итәргә хокуклы.

2. Архитектура-төзелеш проектын төзү төзүченең яки башка хокук иясенеке булган җир кишәрлегенең чикләрендә төзелүче һәм төзекләндерелүче капиталь төзелеш объектларына һәм аларның өлешләренә, шулай ук әлеге статьяның 12_2 өлешендә каралган очракларда капиталь төзелеш объектына капиталь ремонт үткәрү вакытында “Капиталь төзелеш объектына капиталь ремонтка смета” проект документациясе бүлегенә карата кулланылган проект документларын әзерләү юлы белән башкарыла. Әгәр территорияне планлаштыру буенча документлар белән федераль әһәмияттәге транспорт инфраструктурасы объектын яисә төбәк әһәмиятендәге яки җирле әһәмияттәге транспорт инфраструктурасының линия объектын урнаштыру каралган булса, архитектура-төзелеш проектын төзү проект документларын андый объектка һәм аның шул исәптән төзүченеке һәм башка хокук иясенеке (аларга дәүләт хакимияте органнары дәүләт (муниципаль) милек капиталь төзелеш объектларына бюджет инвестицияләрен башкару вакытында (дәүләт органнары), “Росатом” Атом энергиясе буенча дәүләт корпорациясе, дәүләт бюджеттан тыш фондлар белән идарә итү органнары яки җирле үзидарә органнары килешү нигезендә үзләренең дәүләт (муниципаль) заказчы вәкаләтләрен Россия Федерациясенең бюджет законнары белән билгеләнгән очракларда тапшырган) булмаган җир кишәрлеге чикләрендә төзелүче, төзекләндерелүче өлешләренә карата кулланылган проект документларын әзерләү юлы белән башкарыла.

3. Проект документларын әзерләү төзүченең яки техник заказчының (проект документларын әзерләүгә подряд килешүе нигезендә проект документлары әзерләнгән вакытта) биреме, инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләре, җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планында күрсәтелгән мәгълүмат нигезендә, яки линия объектының проект документларын әзерләгән очракта (линия объектын төзү, төзекләндерү өчен территорияне планлаштыру буенча документлар әзерләү таләп ителмәгән очраклардан тыш) территорияне планлаштыру проекты һәм техник регламентлар таләпләре, техник шартлар буенча, рөхсәт ителгән төзелеш, капиталь төзелеш объектларын төзекләндерү чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт белән территорияне межалау проекты нигезендә башкарыла.

4. Төзүче, техник заказчы, бинаны, корылманы эксплуатацияләүгә җаваплы зат, төбәк операторы белән төзелгән проект документларын әзерләү турындагы килешүләр (алга таба шулай ук – проект документларын әзерләүгә подряд килешүләре) буенча эшләр, әгәр башкасы әлеге статьяда каралмаган булса, архитектура-төзелеш проектлаштыруы өлкәсендә үзкөйләнүче оешма әгъзалары булган шәхси эшмәкәрләр һәм юридик затлар белән генә башкарылырга тиеш. Андый килешүләр буенча проект документларын әзерләү буенча эшләр башкару архитектура-төзелеш проектлаштыруын оештыру буенча белгечләр (проектларның баш инженерлары, проектларның баш архитекторлары) белән тәэмин ителә. Башка затлар белән төзелгән проект документларын әзерләү турындагы килешүләр буенча эшләр андый үзкөйләнүче оешмаларның әгъзалары булмаган шәхси эшмәкәрләр һәм юридик затлар тарафыннан башкарыла ала.

Төзүче (заказчы) белән башкаручы арасындагы мөнәсәбәтләр гражданлык законнары белән көйләнә.

Проект документларын әзерләү турындагы килешүне үтәү кысаларында төрле объектларга куллынырга торган әзерләнүче документларның, материалларның составы шәһәр төзелеше турындагы законнар белән билгеләнә: Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Проект документларының бүлекләре составы һәм аларның эчтәлегенә таләпләр турында” 2008 елның 16 февралендәге 87 номерлы карары һәм башка норматив хокукый актлар белән.

5. Проект документларын әзерләү өчен инженерлык тикшеренүләре Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 47 статьясында каралган тәртиптә башкарыла.

Проект документларын әзерләү һәм башкару тиешле инженерлык тикшеренүләрен үтәмичә рөхсәт ителми.

Инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләрен чагылдырган документларның составы һәм формасы шәһәр төзелеше турындагы законнар нигезендә билгеләнә.

Төзүче, техник заказчы яки Россия Федерациясе Җир кодексы нигезендә дәүләт яки муниципаль милектә булган җирләрне яки җир кишәрлекләрен файдаланугa рөхсәт алган зат белән инженерлык тикшеренүләрен башкару турындагы төзелгән килешүләр буенча эшләр, инженерлык тикшеренүләрен башкару өчен (алга таба шулай ук – инженерлык тикшеренүләрен үтәүгә подряд килешүләре), әгәр әлеге статьяда башкасы каралмаган булса, инженерлык тикшеренүләре өлкәсендә үзкөйләнүче оешма әгъзалары булган шәхси эшмәкәрләр һәм юридик затлар белән генә башкарылырга тиеш. Андый килешүләр буенча инженерлык тикшеренүләрен башкару инженерлык тикшеренүләрен оештыру буенча белгечләр (проектларның баш инженерлары) белән тәэмин ителә. Башка затлар белән төзелгән инженерлык тикшеренүләрен башкару турында килешүләр буенча эшләр андый үзкөйләнүче оешмаларның әгъзалары булмаган шәхси эшмәкәрләр яки юридик затлар белән башкарыла ала.

Төзүче (заказчы) белән инженерлык тикшеренүләрен башкаручы арасындагы мөнәсәбәтләр гражданлык законнары белән көйләнә.

Инженерлык тикшеренүләрен башкаручы затлар, законнар нигезендә, проект документларын әзерләү һәм төзелешне башкару вакытында файдаланыла торган инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләре өчен җаваплылык тота.

6. Проект документлары төзүче, техник заказчы, бинаны, корылманы эксплуатацияләү өчен җаваплы зат, яки төбәк операторы белән раслана. Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясында каралган очракларда, төзүче яки техник заказчы проект документларын раслаганчы аны экспертизага җибәрә. Проект документларына экспертизаның уңай нәтиҗәсе булганда гына проект документлары төзүче яки техник заказчы тарафыннан раслана.

24 статья. Төзелешкә рөхсәт бирү

1. Төзелешкә рөхсәт бирү проект документлары шәһәр төзелеше регламенты белән билгеләнгән таләпләргә (җир кишәрлегенә шәһәр төзелеше регламенты көче тимәгән очрактан тыш яки җир кишәрлегенә шәһәр төзелеше регламенты билгеләнмәсә, төзелешкә рөхсәт проект документларының Шәһәр төзелеше кодексының 36 статьясы 7 өлеше белән тәңгәл рәвештә билгеләнгән күрсәтелгән җир кишәрлегендә капиталь төзелеш объектының билгеләнеше, параметлары һәм урнашуы таләпләргә җавап бирүен раслый), территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне межалау проектына (Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә

территорияне планлаштыру проектын һәм территорияне межалау проектын әзерләү таләп ителмәгән очраклардан тыш), линия объекты булмаган капиталь төзелеш объектын төзү, төзекләндерүне башкарган вакытта (алга таба - капиталь төзелеш объектын төзү, төзекләндерүгә таләпләр), яки линия объектын төзү, төзекләндерүне башкарганда территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне межалау проекты белән билгеләнгән таләпләргә (линия объектын төзү, төзекләндерү өчен территорияне планлаштыру буенча документлар әзерләү таләп ителмәгән очраклардан тыш), урнаштыру өчен җир кишәрлеген оештыру таләп ителмәгән линия объектын төзүгә рөхсәт бирелгән очракта территорияне планлаштыру проекты белән билгеләнгән таләпләргә, шулай ук капиталь төзелеш объектын җир кишәрлегендә урнаштыру мөмкин булган андый җир кишәрлеген рөхсәтле файдалану нигезендә һәм Россия Федерациясенең җир һәм башка законнары нигезендә билгеләнгән чикләүләргә җавап бирүен раслаучы документ булып тора

2. Түбән Наратбаш авыл җирлегендә төзелешкә, төзекләндерүгә рөхсәт җирлекнең Башкарма комитеты тарафыннан законнарда каралган очраклардан тыш, әлеге Кагыйдәләрнең 8 статьясы нигезләмәләрен исәпкә алып бирелә.

3. Төзелешкә рөхсәт бирү түбәндәге очракларда таләп ителми:

1) физик затка эшмәкәрлек эшчәнлеге белән бәйле булмаган максатларда бирелгән җир кишәрлегендә гараж төзү, төзекләндерү яки бакча җир кишәрлегендә торак йортны, бакча йортын, хуҗалык корылмаларын төзү, төзекләндерү;

1_1) шәхси торак төзелеше объектларын төзү, төзекләндерү;

2) капиталь төзелеш объекты булмаган объектларны төзү, төзекләндерү;

3) җир участогында ярдәмче файдаланылыштагы төзелешләр һәм корылмалар төзү;

4) капитальтөзелеш объектларының һәм (яки) аларның өлешләрен үзгәртү, әгәр андый үзгәрешләр аларның конструктив һәм башка ышанычлылыгы һәм иминлеге характеристикаларына кагылмаса һәм шәһәр төзелеше регламенты белән билгеләнгән рөхсәт ителгән төзелешнең, төзекләндерүнең чик параметрларыннан артмаса;

4_1) капиталь төзелеш объектларын капиталь ремонтлау;

4_2) җир асты байлыклары турында Россия Федерациясе законнары нигезендә әзерләнгән, килешенгән һәм расланган файдалы казылма ятмаларын эшкәртүнең техник проекты белән яки җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга бәйле эшләрне башкаруга башка проект документлары белән каралган бораулау скважиналарын төзү, реконструкцияләү;

4_4) 0,6 мегапаскальгә кадәр басым астында табигый газны транспортлау өчен билгеләнгән объектларны төзү, төзекләндерү;

5) әгәр Шәһәр төзелеше кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актлары, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында Татарстан Республикасы законнары нигезендә төзелешкә рөхсәт алу таләп ителмәгән башка очракларда.

4. Төзелешкә рөхсәт бирү Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясы нигезендә башкарыла.

25 статья. Төзелеш, төзекләндерү, капиталь ремонт

1. Капиталь төзелеш объектын төзү, төзекләндерү, капиталь ремонт турында төзүче, техник заказчы, бинаны, корылманы эксплуатацияләү өчен җаваплы зат, төбәк операторы белән төзелгән килешү (алга таба – төзелеш подряды килешүе) буенча эшләр, әгәр башкасы әлеге статьяда каралмаган булса, капиталь төзелеш

объектларын төзү, төзекләндерү, капиталь ремонтлау өлкәсендә үзкөйләнүче оешма әгъзалары булган шәхси эшмәкәрләр яки юридик затлар тарафыннан гына башкарылырга тиеш. Андый килешүләр буенча капиталь төзелеш объектын төзү, төзекләндерү, капиталь ремонт буенча эшләр башкару төзелешне оештыру белгечләре (проектларның баш инженерлары) белән тәэмин ителә. Башка затлар белән төзелгән капиталь төзелеш объектларын төзү, төзекләндерү, капиталь ремонтлау турында килешүләр буенча эшләр андый үзкөйләнүче оешма әгъзалары булмаган шәхси эшмәкәрләр һәм юридик затлар тарафыннан башкарыла ала.

2. Капиталь төзелеш объектын төзү, төзекләндерү, капиталь ремонтлауны башкару Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 52 статьясы белән көйләнә.

3. Дәүләт төзелеш күзәтчелеге һәм төзелеш тикшерүе федераль законнар нигезендә башкарыла.

26 статья. Объектны эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирү

1. Объектны эксплуатациягә кертүгә рөхсәт капиталь төзелеш объектын төзү, төзекләндерү, капиталь ремонтлау төзелешкә рөхсәт, проект документлары нигезендә тулы күләмдә башкарылуын, һәм шулай ук төзелгән, төзекләндерелгән капиталь төзелеш объектының, җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планына рөхсәт алу өчен тәкъдим ителгән бирелгән датага билгеләнгән, капиталь төзелеш объектын төзү, төзекләндерү таләпләренә туры килүен, җир кишәрлеген рөхсәтле файдануга яки линия объектын төзү, төзекләндерү очрагында территорияне планлаштыру проектына һәм территорияне межалау проектына (линия объектын төзү, төзекләндерү өчен территорияне планлаштыру буенча документлар таләп ителмәгән очраклардан тыш), линия объектын эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирелгән очракта, аны урнаштыру өчен җир кишәрлеге оештыру таләп ителмәгәндә, территорияне планлаштыру проектына, һәм шулай ук Россия Федерациясенең җир һәм башка законнары нигезендә билгеләнгән чикләүләргә туры килүен раслаучы документ булып тора.

2. Объектны эксплуатациягә кертүгә рөхсәт төзелгән капиталь төзелеш объектын дәүләт исәбенә алу, төзекләндерелгән капиталь төзелеш объектын дәүләт исәбенә алу документларына үзгәрешләр кертү өчен нигез булып тора.

3. Бу статья әлеге Кагыйдәләрнең 2 статьясы 5 өлеше нигезләмәләрен исәпкә алып кулланыда.

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгару көненнән законлы көченә керә һәм http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районы
Түбән Наратбаш авыл җирлеге
башлыгы И.И. Галиуллин